# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«30» май 2016 ел № 7/2

**Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында**

Тукай муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе Р.Л.Гатиятуллинның «Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында» докладын тыңлап, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында» докладны исәпкә алырга.
2. Район Башкарма комитетына:
- конкурс процедураларыннан файдаланып, муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен һәм башка күчемсез мөлкәтне файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру аша җирле бюджетның керем өлешен тулыландыру буенча чаралар күрергә.
3. Тукай муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә:
- айонның җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә 2015 елда коррупциягә каршы мониторинг нәтиҗәләрен җиткерергә, коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча профилактик эшне дәвам итәргә
- 2015 елда коррупциягә каршы мониторингта күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү буенча эш алып барырга, коррупцияне булдырмау буенча максатчан чаралар эшләргә, Сәламәтлек саклау һәм мәгариф учреждениеләрендә контроль механизмнарын кертергә.
4. Районның Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына исәпкә алынмаган һәм нәтиҗәсез файдаланылмый торган милекне исәпкә алу һәм урнаштыру эшен дәвам итәргә, җирләрне читләштерү, муниципаль милекне куллануны контрольдә тоту өлкәсендә хокукка каршы килешү мөмкинлекләрен киметергә.
5. Авыл җирлекләре башлыкларына 2016 ел дәвамында урманнарны һәм су саклау зоналарын законсыз файдалану белән бәйле хокук бозуларны ачыклау өчен халыкны җәлеп итү максатыннан «Халык инвентаризациясе» акциясен үткәрергә тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе — В.Г. Хаҗиев